БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 12 2024 ел № 299

«Балтач муниципаль районы территориясендә 2025-2028 елларга террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында

Халыкта Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен формалаштыру, террорчылык идеологиясен һәм аны пропагандалауны кабул итмәү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге «Иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 764 номерлы карары (2024 елның 22 август редакциясендә ) һәм 2023 елның 30 декабрендәге Пр-2610 номерлы карар белән расланган 2024-2028 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы территориясендә «2025-2028 елларга террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач район башкарма комитеты бүлекләренә һәм идарәләренә, Россия Эчке Эшләр Министрлыгының Балтач муниципаль район бүлегенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балтач районы бүлегенә, Балтач районының иҗтимагый советына үз эш киңәшмәләрендә программаны гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карарга тәкъдим итәргә.

3. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына ел саен Балтач муниципаль район бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштырганда, программа чараларын гамәлгә ашыру өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанс чыгымнарны карарга.

4.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында http://baltasi.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов